МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.10.2017 № 504-пр

г. Казань

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 6 мартындагы № 86-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге №112 Указы белән расланган нигезләмәгә һәм Федераль дәүләт органы кадрлар резервы турында Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 1 мартындагы № 96 Указы белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Россия

Федерациясе Президентының 2017 елның 10 сентябрендәге № 419 Указы нигезендә боерам:

1. «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 6 мартындагы № 86-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктындагы «б» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе белән расланган рәвештә тутырылган һәм имзаланган анкета, фотография теркәп;»;

3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре министр исеменә язылган шәхси гариза һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе буенча расланган рәвештә үз куллары белән тутырылган, имзаланган һәм граждан хезмәткәре вазыйфасын үтә торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган анкетасын, фотографиясен теркәп, Министрлыкка тапшыра.»;

3.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.3, 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документларны Министрлыкка конкурсны үткәрү турында мәгълүмати хәбәр "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Министрлыкның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасында урнаштырылганнан соң 21 көн эчендә граждан (граждан хезмәткәре) шәхсән үзе, почта аша юллап яисә күрсәтелгән мәгълүмати системаны кулланып электрон рәвештә тапшыра.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе буенча билгеләнә.»;

3.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Документларны җитди сәбәпләрсез генә үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыруның җитди сәбәпләре булса, министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.»;

3.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Гражданның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, бу граждан (граждан хезмәткәре) биләүгә дәгъва кыла торган граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны башкару мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булган очракта эшләнә.

Граждан тарафыннан министр исеменә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиешле. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерү аша уза.

Граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, аның Министрлыкның граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә кергән вакантлы граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен конкурска катнашкан очрагында гына тикшерелә.»;

4.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа министр тарафыннан конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында язмача хәбәр ителә. Гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турындагы хәбәр дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә җибәрелә.»;

4.4.4 пунктның беренче абзацын «квалификацион таләпләр» сүзеннән соң «(алга таба – кандидат)» сүзләре белән тулыландырырга;

4.4.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.6. Конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъвачылар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшергәннән соң, шулай ук дәүләт серен һәм бүтән закон белән сакланылучы серне тәшкил итүче белешмәләрне алуны рөхсәт итү кирәк булган очракта, аларны рәсмиләштергәннән соң, министр тарафыннан кабул ителә. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен

документлар кабул итү тәмамланган көннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча уздырыла, дәүләт серен һәм бүтән закон белән сакланылучы серне тәшкил итүче белешмәләрне алуны рөхсәт итү кирәк булган очракта конкурсның икенче этабын уздыру срогы министр тарафыннан билгеләнә.

Министрлыкның кадрлар бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көннән дә соңга калмыйча "Интернет" мәгълүмати- телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталындагы Министрлыкның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасында үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында, конкурста катнашырга үткәрелгән кандидатлар исемлеген урнаштыра, кандидатларга әлеге хәбәрне язмача да юллы, конкурста катнашучы өчен документларын электрон рәвешендә тапшыручы кандадитларга - күрсәтелгән мәгълүмати системаны кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә.»;

4.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац белән тулыландырырга:

«Кадрлар резервына кертелә торган һәр граждан хезмәткәренә (гражданга) Министрлыкның кадрлар бүлеге тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә электрон рәвештәге справка әзерләнә.»;

4.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10. Конкурс нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр конкурс төгәлләнгәннән соң 7 көн эчендә конкурста катнашучыларга язмача рәвештә юллана, конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган кандадитларга – дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә. Конкурс нәтиҗәләре хакында мәгълүмат аны үткәргәннән соң шул ук күрсәтелгән вакыт эчендә «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмати системасында урнаштырыла.»;

4.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11. Граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылган, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында язма гаризалары буенча аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Дәүләт комитеты архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **А.К.Хамаев**